**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧУРАКАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423746, Чуракай авылы,Совет ур., 69 йорт

**СОВЕТ ЧУРАКАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423746, село Чуракаево, ул.Советская, д. 69

**КАРАР**
**17 .09.2019**

**Решение**
**№ 23**

## Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел,№ 67-ФЗ "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 15 статьясы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12, 17 статьялары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Чуракай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Советы

**Карар чыгарды:**

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне инициировать итергә: "2020 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, аларның җирле референдумда катнашуына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, аларның саны җирлек халкының гомуми саныннан 30 процenttан да артмый, алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында: - авыл эчендәге машиналар йөри торган юлларның тозеклеге;

- Чуракай, Иске Әгъбәз авылларында урам утлары чыгымнарын тәэмин иту;

-Чуракай авылында су торбаларын алыштыру, **с**у чыганакларын рэсмилэштеру;

-Чуракай, Иске Әгъбәз авылы зиярат җирләрен рәсмиләштерү

- Зиярат ихаталарын коймалап бетерүне хәл иту

**"ӘЙЕ "** **"ЮК"**

2. Әлеге карар махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган: ТР, Актаныш муниципаль районы, Чуракай авылы, Совет ур., 69 йорт;ТР, Актаныш муниципаль районы, Иске Эгъбэз авылы, Ленин урам, 53 йорт һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыр.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хайдаров